ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 29 марты** **Чистай шәһәре** **№ 174**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының « 2021 елга Чистай
муниципаль районы торак фондында торак
биналарны карап тоту һәм ремонтлау өчен
торак бинадан файдаланган өчен түләү (наем
өчен түләү) күләме турында» 2020 елның 25
декабрендәге 679 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта хезмәт күрсәтүләр һәм идарә итү, тоту һәм ремонт эшләре башкарылган очракта һәм тиешле дәвамлылыктан артып киткән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау эшләре башкарылган очракта торак урынны карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга Чистай муниципаль районының торак фондында торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак урыннарны карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләме турында» 2020 елның 25 декабрендәге 679 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. кушымтаның 2 юлыннан түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга: «Торак бинага капиталь ремонт»; «аена торак урынның кв.м гомуми мәйданы»; «6,11»; «6,11»; «100%».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасары Л.Х. Кашаповага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов